*Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи*

# *Балаларга Иман дәресләре*

(Икенче басма, тулыландырылган һәм төзәтелгән)

Түбән Кама
2009

# Кереш сүз

إن الحمد لله نحمده ونستعينه و نستغفره ونعوذ بالله من شرور أنفسنا ومن سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له ومن يضلل فلا هادي له وأشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له وأشهد أن محمدا عبده ورسوله، وبعد:

Иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ юлы. Шушы ике асыл белән өммәтебезнең әүвәлгеләре туры вә хак юлда булдылар. Ул ике асыл — бу дөньяда да, ахирәттә дә кешенең уңышка вә бәхеткә ирешү юлы. Кем дә кем аларга тотынса — туры юлда булды, ә кем алардан ераклашса, читләшсә — ул адашты вә хәсрәткә батты. «Өммәтебезгә ошбу вакыйгалардан вә төшенкелекләрдән арынып, изге сәләфләр хәленә кайтуыбыз булмаячак, иллә-мәгәр Коръәнне вә пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтен үзебезгә дүстүр[1] итеп алсак кына», — дигән фикергә, көннән көн карашым ныгый.

Аллаһ тәгаләнең рәхмәте илә, бу кыска гына китапны мәктәп яшендәге урта сыйныф балалары өчен динебезне, өммәтебезне

---

1 Төп канун. Бөтен кануннар да шуннан чыгарга вә шуның белән яраштырылырга тиеш

вә милләтебезне күтәрүгә бер сәбәп булсын дип әзерләдем. Шулай ук, ошбу китапны язарга сәбәп вә этәргеч кылган Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнарының Баш Казые Җәлил хәзрәт Фазлыйга үземнең рәхмәтләремне белдерәсем килә. Чөнки ул, 2006-2007 (1427) елның хаҗында миңа үгет вә нәсыйхәтләр кылып, балалар өчен китаплар язуымны дәвам итүемне теләде.

Аллаһ Раббыбыз ошбу эшләребезне Үзенең ризалыгы өчен ихлас кылып, динебезгә файдалы гамәлләрдән әйләсә иде. Бу китапта булган әз генә тырышлык, хәерлесе вә дөресе Аллаһ тәгаләдән:

(وَعَلَّمَكَ مَا لَمْ تَكُنْ تَعْلَمُ) النساء: ١١٣

Мәгънәсе: **«Аллаһ сиңа белмәгәнеңне өйрәтте».**

(وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاء) البقرة: ٢٥٥

Мәгънәсе: «**Аллаһ гыйлеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ теләгәнне генә белерләр».**

Ә анда, хата вә кимчелек булса — минем үземнән вә шәйтаннан:

(قُلْ هُوَ مِنْ عِنْدِ أَنْفُسِكُمْ) آل عمران: ١٦٥

Мәгънәсе: **«Әйт: «Бу үзегезнең нәфсегездән», — диген».**

(وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِلْإِنْسَانِ خَذُولًا) الفرقان: ٢٩

Мәгънәсе: **«Шәйтан кешегә батылны[2] матурлап вә хакны кабәхәт кылып, алдап ташлап китәр булды».**

Аллаһ тәгалә барчабызга һидәят-тәүфыйк бирсен. Кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп итсен.

Я Раббым, безне Үзеңнең туры юлыңнан алып бар, хакны хак итеп белгерт һәм безне хаклыкка якынайт, батылны батыл итеп белгерт һәм безне батылдан ерагайт. Коръән вә Сөннәткә тотынучылардан кыл һәм ихлас-тәкъва бәндәләреңнән әйләп, Үзеңнең рәхмәтең белән Фирдәвес Җәннәтләреңә керт. Әмин!

**Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи**
Хатлар өчен: **mullaniyaz@mail.ru**

2 Дөрес булмаган нәрсә, ялган

## Беренче дәрес

Аллаһ Сөбхәнәһү вә тәгалә барча мәхлукларны[3] фәкать Үзенә генә гыйбадәт кылыр өчен яратты. Аңа һичнәрсәне дә тиңдәш кылмыйча, бер Аны гына олуглап яшәүләре өчен, аларга пәйгамбәрләр җибәреп, китаплар иңдерде.

(وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنْسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ) الذاريات: ٥٦

Мәгънәсе: **«Җеннәр белән кешеләрне, иллә-мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халикъ кылдым».**

(وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا) النساء: ٣٦

Мәгънәсе: **«Аллаһның Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз».**

Аятьләрдән күренгәнчә, Аллаһ тәгалә Үзенә генә гыйбадәт кылып, Аңа һичкемне тиңдәш итмәскә боерды.

### Нәрсә ул гакыйдә?

Гакыйдәнең тел сүзлегеннән булган мәгънәсе, ул — бәйләнеш, яки бер нәрсәнең башка әйбергә бәйләнеүен аңлата. Шуңа да, кеше үзенең йөрәген нәрсәгәдер бәйләгән өчен — гакыйдә, дип атала. Мәсәлән: Коммунистларның үз гакыйдәләре, чөнки алар йөрәкләрен үзләре

3 Аллаһ тарафыннан бар ителгән затлар

ышанган нәрсәгә бәйләгән. Шулай ук, нәсаралар (христианнар), яһүдләр, мәҗүсләр һәм башкалар, аларның һәрберсенең үз гакыйдәсе вә үз юлы, чөнки аларның йөрәкләре үзләренең ышанган нәрсәләренә бәйләнгән.

Гакыйдә ул — йөрәк гамәле, ягъни йөрәкнең нәрсәгәдер ышанып, аны тәсдыйклап (раслап), шуңа бәйләнүе. Башкача әйткәндә, кешенең тоткан дине.

### Нәрсә ул Ислам гакыйдәсе?

Ислам гакыйдәсе, ул — Аллаһ тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә һәм тәкъдирнең яхшысына да, яманына да иман китерү. Шулай ук, бу — "Иман нигезләре", дип тә атала.

### Нәрсә ул тәүхид?

**Тәүхид, ул — гыйбадәттә бер Аллаһны гына тану һәм Ул гына гыйбадәткә лаек дип белү.** Ягъни — рубубияда да, үлүһиядә дә һәм әләсмәә вә әс-сыйфатта да бер Аны гына тану.

### Тәүхиднең төрләре:

Тәүхид өч төрле:

**Тәүхид рубубия.** Ул — Аллаһ тәгалә барча нәрсәне халикъ кылучы, ризыкландыручы, бар итүче вә үлекләндерүче — дип, Аңа ныклы ышану, «Раббы нәрсәне теләсә, шуны эшли», —

дип иман китерү була. Пәйгамбәребез ﷺ вакытында, хәтта Мәккә мөшрикләре дә бу тәүхидне таныйлар иде:

(وَلَئِنْ سَأَلْتَهُمْ مَنْ خَلَقَهُمْ لَيَقُولُنَّ اللَّهُ) الزخرف: ٨٧

Мәгънәсе: **«Әгәр син алардан: «Сезне кем халикъ кылды?», — дип сорасаң, алар, әлбәттә: «Аллаһ халикъ кылды», — диячәкләр».**

**Тәүхид үлүһия.** Ул — хакыйкатьтә, бер Аллаһ Сөбхәнәһү вә тәгалә генә хакыйкый гыйбадәткә лаек — дип тану. Ошбу тәүхидне мөшрикләр кабул итмичә инкяр иттеләр һәм шушы тәүхидтә пәйгамбәрләр белән алар арасында каршылык килеп чыкты.

**Тәүхид әл-әсмәә вә әс-сыйфаат.** Ул — Аллаһ тәгалә Үзен Коръәндә һәм пәйгамбәребез ﷺ Аны сөннәтендә сыйфатлаган күркәм исемнәр вә камил сыйфатлар белән сыйфатлау.

## Гакыйдә һәм гыйбадәт дөрес булуының шартлары:

Гакыйдә дөрес булсын өчен ике шартның үтәлүе тиеш:

**1) Ихласлылык.** Барча гамәлләребез дә Аллаһ ризалыгы өчен ихластан булып, рия вә нифактан булмаска тиеш. (Рия — башка кешеләр күрсен дип эшләнгән гамәл. Нифак — тышкы гамәлләре белән мөселманнар

кебек гамәл итеп, эчтән, күңеленнән Аллаһ тәгаләгә ышанмыйча көферлек кылу).

**2) Мүтәбәга.**[4] Ул — барча нәрсәдә дә пәйгамбәребез ﷺ алып килгән шәригать буенча гамәл итү, яки яшәешебездә расүлебезгә иярү. Шуңа да, мөселманның төп чыганагы булып Коръән вә пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәте булырга тиеш.

Ихласлылык белән мүтәбәга, мөселман кешесен Аллаһка якынайта торган барча изге гамәлләрдә дә шарт булып тора. Әгәр дә бу ике шартның берсе генә дә булмаса, гамәл дөрес булмый.

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Аллаһ тәгалә барча мәхлукларны ни өчен халикъ кылды? Коръәннән моңа нинди аятьне дәлил итеп китерә аласың?

2) Нәрсә ул гакыйдә, Ислам гакыйдәсе һәм тәүхид?

3) Тәүхид әл-әсмәә вә әс-сыйфат нәрсә була, әйтеп бир?

4) Мәккә мөшрикләре нинди тәүхидне таныдылар?

4 Мүтәбәга: гарәп сүзе: иярү, кемнең дә булса эзеннән бару

5) Нинди тәүхидне мөшрикләр инкяр иттеләр?

6) Гакыйдәнең дөрес булуы өчен нинди шартлар үтәлергә тиеш?

7) Нәрсә ул мүтәбәга?

\- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Хакыйкатьтә, бер Аллаһ кына ____________________ лаек.

2) Тышкы гамәлләре белән ________________ кебек гамәл итеп, эчтән, күңеленнән ____________________ ышанмыйча көферлек кылу, ул ____________________ дип атала.

3) Коръән һәм пәйгамбәребезнең ﷺ ______________ мөселманның ___________________ чыганагы.

4) Хакыйкатьтә, бер ____________________ Сөбханәһү вә тәгалә генә ____________________ лаек дип икърар итү, ул тәүхид ____________________.

# Икенче дәрес

## Зур һәм кечкенә ширек

Ширек, куркыныч булган олуг гөнаһлардан. Чөнки ул, кешене Исламнан чыгарып, бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеттән мәхрүм итә. Аллаһ тәгалә кешеләрне бик нык кисәтеп, ширектән сакланырга кушты һәм мөшрикләрне гафу итмәячәклеге хакында Коръәндә болай диде:

(إِنَّ اللَّهَ لَا يَغْفِرُ أَنْ يُشْرَكَ بِهِ وَيَغْفِرُ مَا دُونَ ذَلِكَ لِمَنْ يَشَاءُ وَمَنْ يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدِ افْتَرَى إِثْمًا عَظِيمًا) النساء: ٤٨

Мәгънәсе: **«Аллаһ үзенә ширек кылуны гафу итмәс, ширек кылудан башка гөнаһларны Үзе теләгән кешедән гафу итәр. Бер кеше Аллаһка кемнедер, нәрсәнедер тиңдәш кылса, дөреслектә, ул Аллаһка олы ялганны яла ягучы булды».**

Икенче бер аятьтә Аллаһ ﷻ мөшрикләргә Җәннәтне хәрам итте һәм Җәһәннәм белән вәгъдә кылды:

(إِنَّهُ مَنْ يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدْ حَرَّمَ اللَّهُ عَلَيْهِ الْجَنَّةَ وَمَأْوَاهُ النَّارُ وَمَا لِلظَّالِمِينَ مِنْ أَنْصَارٍ) المائدة: ٧٢

Мәгънәсе: **«Бер кеше Аллаһка ширек кылса, чынлыкта, Аллаһ ул кешегә Җәннәтне хәрам кылды һәм аның кайтачак урыны — Җәһәннәм. Ахирәттә залимнәргә ярдәмче булмас».**

Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ үзенең бер хәдисендә: кемдә кем Аллаһка башка берәүне тиңдәш кылса һәм тәүбә итмичә үлеп китсә, ул Җәһәннәм әһеленнән булыр дип белгертте:

«مَنْ مَاتَ وَ هُوَ يَدْعُو مِنْ دُونِ اللهِ نِدًّا
دَخَلَ النَّار» (رواه البخاري)

Мәгънәсе: ***«Берәү Аллаһка ширек кылган килеш үлсә, ул Җәһәннәм утына керер».***

Ибраһим عليه السلام үзе өчен дә, балалары өчен дә ширектән ерак булуны теләде һәм Раббысына болай дип дога кылды:

(وَاجْنُبْنِي وَبَنِيَّ أَنْ نَعْبُدَ الْأَصْنَامَ) إبراهيم: ٣٥

Мәгънәсе: **«Вә үземне һәм балаларымны сыннарга гыйбадәт кылудан сакла!».**

## Ширек ничәгә бүленә?

Ширек ике төрлегә бүленә: зур ширек һәм кечкенә ширек:

**Зур ширек** — Аллаһ тәгаләгә генә хас булган нәрсәләрдә Аңа башканы тиңдәш кылу (сәҗдә, дога, корбан чалу һ.б.)

**Кечкенә ширек** — Коръән һәм Сөннәттә ширек дип исемләнгән булса да, зур ширек дәрәҗәсенә җитмәгән гамәлләр. Мәсәлән: «Аллаһ вә синең теләгең белән», — дип әйтү, рия кылу, Аллаһтан башка белән ант итү һ.б.

**Зур ширек белән кечкенә ширек арасындагы аермалар:**

– Зур ширек барча кылган гамәлләрне дә юкка чыгара, ә кечкенә ширек нинди гамәлдә күренсә, шуны гына юкка чыгара. Мәсәлән, **зур ширек:** Бер кеше гомер буе намаз укып, ураза тотып Исламча яшәргә тырышкан, әмма ләкин көннәрнең берендә үлгән әнисенең каберенә барып, мәетне зурлап корбан чала, яки әнисенең сурәтен алдына куеп аңа сәҗдә кыла башлый. Бу эшләрдән соң аның элек кылган барча изгелекләре дә юкка чыга һәм ул Исламнан чыгып китә. Аллаһ сакласын! **Кечкенә ширек:** Бер кеше мәчеткә кереп, башка иптәшләре аны күрсеннәр һәм: «Менә бу кеше иманлы да инде!», — дип әйтсеннәр өчен, намазны озак итеп укый. Бу — рия, дип атала. Шуңа да, рия белән кылынган гамәл дөрес булмый, ә инде элек кылган изге гамәлләренә зыян килми, иншәАллаһ.

– Зур ширек кешене мәңгелек Җәһәннәмдә калдыра, ә кечкенә ширек кешене мәңгелек Җәһәннәмдә калдырмый.

– Зур ширек кешене Ислам милләтеннән чыгара, ә кечкенә ширек Ислам милләтеннән чыгармый.

Ничек кенә булса да, мөселман кешесе зур ширектән дә, кечкенә ширектән дә сакланыр-

га һәм Аллаһ тәгаләгә сыенып дога кылырга тиеш.

## Күнегүләр

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Аллаһ тәгалә мине ____________________ ерагайтсын дип, Аңа дога кылдым.

2) Аллаһ тәгалә мөшрикләргә _____________ вәгъдә итте.

3) Кечкенә ширек _________________ милләтеннән чыгармый.

4) Зур ширек кешене ____________________ илтә һәм ____________________ чыгара.

5) Аллаһ тәгаләгә _______________________ юк.

- Түбәндәге гамәлләрнең нинди ширеккә китергәнен билгелә:

а) Аллаһтан башка белән ант итү.

б) Рия.

в) Аллаһтан башкага корбан чалу.

г) Аллаһтан башкага сәҗдә кылу.

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Зур ширек белән кечкенә ширек арасында нинди аермалар бар?

2) Кечкенә ширеккә ике мисал китер.

3) Аллаһтан башкага сәҗдә кылу нәрсәгә илтә?

4) Кыямәт көнендә мөшриккә нинди җәза бирелә?

5) Әйткәнеңә Коръәннән дәлил китер?

6) Аллаһ тәгалә ни өчен ширектән сакланырга кушты?

7) Кечкенә ширек Исламнан чыгарамы?

## Өченче дәрес

### Ширекнең төрләре

**1. Аллаһтан башка белән ант итү:** Ант — ул, нинди дә булса олуглаган һәм хөрмәт иткән әйбернең исемен искә алып, бер төрле гамәлне эшләргә яки эшләмәскә, нәрсәнең дә булса булганлыгын яки булмаганлыгын катгый рәвештә белгертү.

Белүебезчә, олуглау вә бөекләү, ул — Аллаһ тәгаләгә генә хас. Шуңа да, башка нәрсәләр сиңа ничек кенә кадерле вә хөрмәтле булмасын, булсын ул пәйгамбәребез ﷺ яки әниебез, әтиебез, балабыз, әмма ләкин аңа карамастан, ант итү бер Аллаһ исеме белән генә яки Аның күркәм сыйфатлары белән генә булырга тиеш. Аллаһтан башка нәрсәләр белән ант итүне тыеп бик күп хәдисләр килде. Без шуларның берничәсен әйтеп узарбыз:

«مَنْ حَلَفَ بِغَيْرِ اللهِ فَقَدْ كَفَرَ أَوْ أَشْرَكَ» (الترمذي)

Мәгънәсе: ***«Кем дә кем Аллаһтан башка белән ант итсә, ул көферлек кылды яки ширек катты».***

«إِنَّ اللهَ يَنْهَاكُمْ أَن تُحْلِفُوا بِآبَائِكُمْ، مَنْ كَانَ حَالِفاً
فَلْيَحْلِفْ بِاللهِ أَوْ لِيَصْمُتْ» (البخاري)

Мәгънәсе: ***«Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгаләсезгә аталарыгыз белән ант итәргә тыйды, әгәр дә***

***бер кеше ант итсә — Аллаһ белән ант итсен, яки бөтенләй дәшмәсен».***

Шулай итеп, Ислам безне Аллаһтан башка белән ант итүдән тыйды. Ләкин, күп кенә кешеләр моны белмичә әти-әнисе яки ватаны, икмәк, тоз, үлгәннәр һәм башка ярамаган нәрсәләр белән ант итәләр. Әгәр дә танышларыбыздан кемдә булса шулай эшләгәнен күрсәк, без аңа, моның динебездә ярамаганлыгын хикмәт вә йомшаклык белән аңлатырга тиешбез.

Шулай ук, шәригатебездә тыелган нәрсәләрдән: Аллаһ тәгаләгә башка бер затны тиңләп сөйләү һәм нинди дә булса нәтиҗәне шул затка бәйләү. Мәсәлән: «Аллаһ вә фәлән теләге белән», «Әгәр дә ошбу дару яки бу табиб булмаса, үлгән булыр идем», «Әгәр дә ошбу эт булмаса, караклар талап киткән булыр иде», — дигән кебек сүзләр. Болар һәммәсе дә Аллаһ белән бәйләнергә тиеш. Шулай ук, аның ахырында: «Һәм шуннан соң фәлән», — дип, икенче затны тоташтырырга мөмкин: «Әгәр Аллаһ сакламаса һәм шуннан соң бу табиб булмаса, үлгән булыр идем», «Бар нәрсә дә Аллаһ теләге белән генә», — дигән мәгънәдә әйтелергә тиеш.

**2. Бәла-казадан саклану өчен дип, бөти яки җеп кебек нәрсәләр бәйләү.** Кайбер кешеләр күз тиюдән, бәла-казалардан, чирләрдән сак-

ланырга дип муеннарына, кулларына, машиналарына һәм башка урыннарга бөти яки төрле җепләр бәйлиләр. Акылы камил булган мөселман кешесенә бу нәрсәләр һич тә дөрес булмас. Чөнки һәрнәрсә Аллаһ кулында, шуңа да, без Аңа гына сыенып, Аннан гына ярдәм сорарга тиешбез. Бу хакта пәйгамбәребез ﷺ үзенең бер хәдис-шәрифендә болай дип әйтеп узды:

عن عمران بن حصين رضي الله عنه أن رسول الله صلى الله عليه و سلم رَأى رَجُلاً فِي يَدِهِ حَلْقَةٌ مِنْ صُفْرٍ فَقَالَ: «مَا هَذِهِ؟» قَالَ: مِنَ الْوَاهِنَةِ، فَقَالَ: «انْزِعْهَا فَإِنَّهَا لا تَزِيدُكَ إِلاَّ وَهْناً، فَإِنَّكَ لَوْ مِتَّ وَ هِيَ عَلَيْكَ مَا أَفْلَحْتَ أَبَداً» (مسند الإمام أحمد)

Мәгънәсе: «Гыймран бин Хөсәйннән ؓ: Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ бер кешенең кулында бакырдан ясалган беләзек күрде һәм: ***«Бу нәрсә?»,*** — дип сорады, теге кеше: «Үәһинәдән (кулга хәлсезлек китерә торган чирдән)», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Тартып алып ташла аны, чөнки ул сиңа хәлсезлектән башка һичнәрсә дә өстәми, әгәр дә ул әйберне таккан килеш үлеп китсәң, беркайчан да уңышка вә бәхеткә ирешмәссең».***

Шулай ук, Хүзәйфә ؓ бер кешенең кулында бизгәк авыруыннан саклану өчен бәйләнгән җепне күреп тартып өзде дә, түбәндәге аятьләрне укыды:

﴿وَمَا يُؤْمِنُ أَكْثَرُهُمْ بِاللَّهِ إِلَّا وَهُمْ مُشْرِكُونَ﴾ يوسف: ١٠٦

Мәгънәсе: **«Аларның күбрәге Аллаһка иман китермәсләр, мәгәр иман китерсәләр кемне яки нәрсәне булса да Аллаһка тиңдәш кылып мөшрик булырлар».**

**3. Аллаһтан башкага корбан чалу.** Корбан чалу ул — гыйбадәт, шуңа да аны Аллаһтан башкага сарыф итү зур ширеккә керә. Коръәндә Аллаһ тәгалә корбан чалуны намаз белән янәшә билгеләде һәм әйтте:

(فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ) الكوثر: ٢

Мәгънәсе: **«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм корбан чал!».**

Намаз — тән гыйбадәтләренең иң яхшысы, ә корбан чалу — мал гыйбадәтләренең иң яхшысы. Шуның өчен намазны да, корбан чалуны да Аллаһтан башкага сарыф итәргә ярамый. Кем дә кем нинди дә булса бер төрле гыйбадәтне Аллаһтан башкага сарыф итсә, ул мөшрик була. Аллаһ сакласын!

Аллаһтан башкага корбан чалу иң зур гөнаһлардан икәнлеген бәян итеп пәйгамбәребез ﷺ болай диде:

«لَعَنَ الله مَنْ ذَبَحَ لِغَيْرِ الله» ( مسلم )

Мәгънәсе: ***«Аллаһтан башкага корбан чалучыны Аллаһ ләгънәт кылды».***

**4. Әүлияләр каберләрен зиярат кылу өчен сәфәр итү.**

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «لاَ تَجْعَلُوا بُيُوتَكُمْ قُبُورًا وَلاَ تَجْعَلُوا قَبْرِى عِيدًا وَصَلُّوا عَلَىَّ فَإِنَّ صَلاَتَكُمْ تَبْلُغُنِى حَيْثُ كُنْتُمْ» (أبو داوود، صحيح)

Мәгънәсе: Әбү Сәгыйдтән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Йортларыгызны кабер кылмагыз вә минем каберемне бәйрәм, гыйбадәт урыны итмәгез! Миңа салават әйтегез! Чөнки сез кайда гына булсагыз да, ул миңа ирешә».***

Шулай итеп, расүлебез ﷺ өммәтен ширектән сакларга тырышып, хәтта үзенең каберен дә бәйрәм вә гыйбадәт урынына әйләндерүдән катгый рәвештә тыйды. Кешеләрнең ныклы гадәтенә әйләнмәсен өчен, имам Мәлик Мәдинә әһелләренә пәйгамәребезнең ﷺ каберенә даими рәвештә килүне мәкрүһ күрә иде.

**5. Кешеләрнең каберләр янында кыла торган гамәлләре ике төрле: *Рөхсәт ителгән һәм тыелган.***

***Рөхсәт ителгән:*** Ул гамәлләрне пәйгамбәребез ﷺ үзенең шәригатендә бәян итеп калдырды. Мәсәлән: мөселман кешесенең сөннәт буенча каберләргә зиярат кылуы, үлгәннәргә гомуми итеп, ә вафат булган туган-кардәшләренә, белгәннәренә аерым-хосусый итеп дога кылуы. Болар барысы да мәетләргә

аның тарафыннан изгелек һәм үзенә ахирәтне искә алу була.

***Тыелган гамәлләр үзләре икегә бүленәләр:***

**Беренчесе:** Хәрам һәм ул ширеккә китерә торган гамәл. Мәсәлән: Бәрәкәт өмет итеп каберләрне сыпыру, анда намазлар уку, шәмнәр куеп яки башкача ул каберләрне яки үлеләрне бөекләү, олуглау, данлау һәм башкалар. Болар һәммәсе дә хәрам вә ширеккә китерә торган гамәлләр. Аллаһ сакласын!

**Икенчесе:** Көферлек. Мәсәлән: Кабердәге мәетләрдән нәрсә дә булса дөньялык яки ахирәт өчен сорау, аларга сыену вә алар файда яки зыян китерә ала дип ышану. Мондый гамәлләрне кәферләр үзләренең каберләре янында кылалар. Бу зур ширеккә керә һәм мөселман кешесен Ислам милләтеннән чыгарып, көферлеккә кертә. Чөнки, без беләбез, Аллаһтан башка һичнинди зат файда да, зыян да итә алмый, һәм барча олуглаулар, мактаулар, ул — Аллаһка гына хас.

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Нәрсә ул ант?

2) Нинди дә булса бер әйбер белән ант итү нәрсәне аңлата?

3) Бер кеше Аллаһтан башка белән ант итсә, аңа нинди хөкем була? Әйткән сүзеңә дәлил китер.

4) Авырулардан яки күз тиюдән сакланып бөти, җепләр бәйләүнең хөкеме нинди?

5) Аллаһтан башкага корбан чалуның хөкеме нинди? Сүзеңне Коръән яки хәдис белән аңлат.

6) Ни өчен Коръән аятендә намаз белән корбан чалу янәшә килде?

7) Каберләргә зиярат кылуның рөхсәт ителгәнен аңлат.

8) Каберләргә зиярат кылуның тыелганын аңлат.

9) Үзеңнең авылыңда яки шәһәреңдә каберләргә ни рәвешле зиярат кылынганын сөйләп уз һәм хата булган гамәлләрне билгелә.

# Дүртенче дәрес

## Мәетләр белән тәбәррүк кылу

Мәетләр белән тәбәррүк кылу, ул — алардан бәрәкәт таләп итү һәм анын сиңа ирешүен өмет итү. Кем дә кем мәетләргә мөрәҗәгать итеп, файда яки бәрәкәт таләп итсә, ул кеше Аллаһтан башканы үзенә «иләһ» вә «раббы» итеп алган була. Нух ﷺ кавеменең һәм дә аннан соң килгән кавемнәрнең ширек кылулары шушы төрдән булды. Алар да мәетләрне зурлап, үзләренең төрле хаҗәтләрен вә теләкләрен тормышка ашыруны сорап кабер әһелләренә мөрәҗәгать итәләр иде. Шәйтан — ләгънәт төшкере, ул кешеләрне шул кадәр адаштырган иде, хәтта алар мәетләр ишетәләр вә аларга ярдәм итә алалар дип ышаналар иде. Әгәр дә ул адашкан кешеләр тәкәбберләнмичә пәйгамбәрләргә иман китерсәләр, әлбәттә хаклыкны белерләр иде.

(وَمَنْ أَضَلُّ مِمَّنْ يَدْعُو مِنْ دُونِ اللَّهِ مَنْ لَا يَسْتَجِيبُ لَهُ إِلَى
يَوْمِ الْقِيَامَةِ وَهُمْ عَنْ دُعَائِهِمْ غَافِلُونَ ۞ وَإِذَا حُشِرَ النَّاسُ
كَانُوا لَهُمْ أَعْدَاءً وَكَانُوا بِعِبَادَتِهِمْ كَافِرِينَ) الأحقاف: ٥-٦

Мәгънәсе: **«Аллаһтан башка затка гыйбадәт кылучы кешедән дә адашучырак кеше бармы? Догаларын, сораганнарын кабул итәргә, нәрсәдер бирергә мәңге көчләре җитми торган**

**сыннарга гыйбадәт кылалар, хәлбуки, бу сыннар аларның догаларыннан гафилләр, чөнки алар җансызлар. Кешеләр каберләрдән кубарылганда, сыннар аларга гыйбадәт кылучыларга дошман булырлар вә мөшрикләрнең аларга кылган гыйбадәтләрен инкяр итәрләр».**

Бу аятьләрдән күренгәнчә түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә мөмкин:

**1)** Сорала торган мәет таләп итүчегә җавап бирми.

**2)** Мәет сораучыдан һәм соралган әйберләрдән гафил, һичнәрсә ишетми вә белми.

**3)** Мәет Кыямәт көнендә, аннан сораучы тере кешегә дошман булачак.

Хәзерге көндә күп кенә мөселманнар гыйлемсезлекләре сәбәпле каберләргә барып, динебез кушмаган гамәлләр кылалар, зур хаталар ясыйлар. Шуңа да без белгәнебезне башкаларга да өйрәтеп, аларны шәригатебез кушмаган вә Җәһәннәмгә илтә торган шәйтан гамәлләреннән тартып алып, саф динебезгә, пәйгамбәребез ﷺ күрсәткән хак юлга өндәргә тиешлебез.

## Күнегүләр

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Кем дә кем мәетләрдән ________________ таләп итә икән, ул аларны үзенә ________________ итеп алган була.

2) Ислам, ________________ сыпырып тәбәррүк кылуны тыйды.

3) Аллаһ тәгалә ____________________ Кыямәт көнендә каберләреннән кубарачак.

4) Мәетләр белән ________________ кылу, ул алардан ________________ таләп итү һәм аның ________________ өмет итү.

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Нәрсә ул мәетләр белән тәбәррүк кылу?

2) Мәетләрдән бәрәкәт таләп итүнең хөкеме нинди?

3) Мәетләр, сораучы тере кешеләрнең сүзләрен ишетәләрме? Әйткән сүзеңә дәлил китер.

# Бишенче дәрес

## Аллаһның күркәм исемнәре һәм камил сыйфатлары

### Аллаһ тәгаләнең күркәм исемнәренә вә сыйфатларына иман китерүнең мәгънәсе:

Мөселман кешесенең Коръәнгә вә Сөннәткә ныклы итеп тотынып, анда килгән Аллаһның исемнәренә вә сыйфатларына иман китерүе — Раббыбызның безгә карата булган зур нигъмәтләреннән. Шуңа да дөрес гакыйдәле мөселман Раббысын беркайчан да мәхлукларга охшатмас һәм беркайчан да Аллаһ Үзен Коръәндә вә пәйгамбәребез ﷺ Аны сөннәтендә билгеләгән исем-сыйфатларны үзгәртеп сөйләмәс.

Аллаһ тәгаләнең сыйфатлары хакында сөйләшүебез, Аның заты хакында сөйләшүебез кебек. **Аллаһның заты — башка затларга охшамаган һәм Аның сыйфатлары — башкалар сыйфатына охшамаган.** Моңа дәлил итеп Коръәннән түбәндәге аятьләрне китерергә мөмкин:

(لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ) الشورى: ١١

Мәгънәсе: **«Аллаһка охшаган һичнәрсә юк вә Ул һәрнәрсәне ишетүче вә күрүче».**

Билгеле булганча, Аллаһ тәгаләнең ишетүе вә күрүе — Раббыбызның Үзенә генә хас, безнең ишетү вә күрү кебек түгел, чөнки мәхлукларның ишетү вә күрүләре — үзләренә хас. Имамыбыз Әбү Хәнифә бу хакта болай диде: ***«Ул (Аллаһ) — мәхлукларга һичнәрсәдә дә охшаш түгел», һәм дәвам итеп: «Аның сыйфатлары һич тә мәхлукларныкына охшамаган, гыйлеме — безнең гыйлем кебек түгел, кодрәте — безнең кодрәт кебек түгел, күрүе — безнең күрү кебек түгел».*** Имам Бохариның остазы Нәгыйм бин Хәмәд болай диде: ***«Кем дә кем Аллаһ тәгаләне мәхлукларга охшатты исә — ул кәфер булды һәм кем дә кем Аллаһ Үзен сыйфатлаган сыйфатны инкяр итте исә — ул кәфер булды. Аллаһ Үзен сыйфатлаган сыйфатлар белән пәйгамбәребез ﷺ Аны сыйфатлаган сыйфатлар арасында, мәхлукатларга тәшбих кылу (охшату) юк».***

Белгәнебезчә, Аллаһ тәгаләнең күркәм исемнәре бар һәм Ул шушы исемнәр белән колларына дога кылырга кушты:

(وَلِلَّهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَى فَادْعُوهُ بِهَا) الأعراف: ١٨٠

Мәгънәсе: **«Аллаһның күркәм исемнәре бар, шул исемнәр белән дога кылыгыз!».**

Һәм ошбу исемнәрдә көферлек кылудан сакланырга әмер итте:

(وَذَرُوا الَّذِينَ يُلْحِدُونَ فِي أَسْمَائِهِ سَيُجْزَوْنَ
مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ) الأعراف: ١٨٠

Мәгънәсе: **«Әмма Аллаһка тиешсез исем бирүчеләрдән (Аның исемнәрендә илхәд кылучылардан) качыгыз! Ошбу эшләгән гамәлләре өчен җәза кылынырлар».**

Шулай ук, Аллаһ тәгалә Үзенең камил сыйфатлары белән мактарга һәм Аны бөекләп һәр кимчелектән, җитешсезлектән пакьләргә боерды:

(الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ
۞ مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ) الفاتحة: ٢ - ٤

Мәгънәсе: **«Барча чын камил сыйфатлар белән мактау, галәмнәрне вә бөтен мәхлукларны тәрбияләүче Аллаһ тәгаләгә тиешле. Аллаһ тәгалә бу дөньяда барча кешеләргә мәрхәмәтле, ягъни мөэминнәргә дә, кәферләргә дә нигъмәтләрен бирә, әмма ахирәттә, мөэмин бәндәләренә генә бирәчәк. Аллаһ тәгалә гаделлек белән хөкем итүче, Кыямәт көненең патшасы».**

(سُبْحَانَ رَبِّكَ رَبِّ الْعِزَّةِ عَمَّا يَصِفُونَ ۞ وَسَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ
۞ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ) الصافات: ١٨٠ - ١٨٢

Мәгънәсе: **«Барча кимчелектән пакь булган синең Раббың, өстенлек һәм кодрәт Раббысы, Ул мөшрикләр сыйфатлаган нәрсәләрдән пакь. Вә барча пәйгамбәрләргә Аллаһның сәламе бул-**

**сын! Вә барча галәмне тәрбия итүче Аллаһка — мактау булсын!».**

## Күнегүләр

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Мөселман үзенең Раббысына __________ әйтә.

2) Аллаһ тәгалә Үзен барча ________________ вә __________________ пакьләргә боерды.

3) Мөселманнар ____________________________ һәм _________________________ нык итеп тотыналар.

4) Әгәр дә кеше Аллаһны ______________ охшатса, ул ______________ була.

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Мөселман кешесе Аллаһка нинди сыйфатларны тәсбит кылырга (расларга) тиеш?

2) Ошбу аятьне аңлат:

(لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ) الشورى: ١١

Мәгънәсе: «**Аллаһка охшаган һичнәрсә юк вә Ул һәрнәрсәне ишетүче вә күрүче**».

3) Әгәр дә берәү Аллаһны мәхлукларга охшатса, ул кешегә нинди хөкем булыр?

4) Әгәр дә берәү Аллаһ тәгалә Үзен сыйфатлаган сыйфатларны инкяр итсә, аңа нинди хөкем булыр?

5) Имамыбыз Әбү Хәнифә хәзрәтләре Аллаһ тәгаләнең сыйфатлары хакында нәрсә әйтте?

6) Имам Бохариның остазы нинди караште?

## Алтынчы дәрес

### Иманның тармаклары

Аллаһка иман — кеше белән Раббысы арасындагы иң зур вә иң көчле бәйләнеш. Кеше җир йөзендә иң затлы вә иң гүзәл мәхлуклардан, ә иман — кешегә бирелгән иң зур нигъмәтләрдән.

Иманның бик күп тармаклары бар. Пәйгамбәребез ﷺ үзенең бер хәдис-шәрифендә болай диде:

«الإِيمَانُ بِضْعٌ وَسَبْعُونَ أَوْ بِضْعٌ وَسِتُّونَ شُعْبَةً فَأَفْضَلُهَا قَوْلُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَأَدْنَاهَا إِمَاطَةُ الأَذَى عَنِ الطَّرِيقِ وَالْحَيَاءُ شُعْبَةٌ مِنَ الإِيمَانِ» (رواه مسلم)

Мәгънәсе: ***«Иманның җитмештән, яки алтмыштан артык тармагы бар, иң яхшысы вә югарысы — «Лә иләһә иллә Аллаһ», — дип әйтү, иң түбәне — юлдан киртәне яки йөрүчеләргә авырлык китерә торган нәрсәне алып ташлау, оялчанлык — иманның бер тармагы».***

### Иманның мәгънәсе:

***Иман — ул, тел белән әйтү, йөрәк белән раслау, ныгыту вә тән белән гамәл итү.*** Аллаһтан һәм Аның расүленнән килгән һәрнәрсә дөрес вә тугры дип ныклы ышану һәм хәрамнардан

сакланып, өстебезгә йөкләнгән гамәлләрне үтәүдә җидти булу.

**Гөнаһларның иманга тәэсир итүе:** Гөнаһ эшләү, ул — Аллаһка булган итагатьлектән чыгу. Кем дә кем зур яки кечкенә гөнаһ кылды исә, ул буйсынмаучы, киреләнүче була. Аллаһка ширек кылучыдан башка, гөнаһ кылучы Исламнан чыкмый, бәлки гөнаһ эшләүче мөэмин булып кала. Әмма аның гөнаһ кылу сәбәпле иманы кими вә зәгыйфьләнә, чөнки гөнаһ кылу иманга тискәре тәэсир итә.

**Гөнаһларның төрләре:** Гөнаһлар ике төрле: **Зур гөнаһлар** һәм **кечкенә гөнаһлар.**

**Зур гөнаһлар,** алар шундый гөнаһлардыр, аларга бу дөньяда шәригать буенча җәза бар һәм Кыяматтә аңа ләгънәт, яки Җәһәннәм уты, яки Аллаһның ачуы, яки иманның юкка чыгуы кебек, ахирәт җәзасы бар. Зур гөнаһлар күптер, иң куркынычы вә олысы — ширек, ул иманны бөтенләй юкка чыгара. Шулай ук, зур гөнаһлардан — зина, кеше үтерү, сихер, җиһәд мәйданыннан качу, ятимнәр малын ашау, риба, əти-әнигә карышу, ялган ант итү һәм башкалар.

**Кечкенә гөнаһлар** өчен бу дөьяда да, ахирәттә дә җәза билгеләнмәгән, ләкин мөселман кешесе аны эшләүдән сакланырга тиеш, чөнки кечкенә гөнаһларны даими рәвештә эшләү, зур гөнаһка әйләндерә.

(إِنْ تَجْتَنِبُوا كَبَائِرَ مَا تُنْهَوْنَ عَنْهُ نُكَفِّرْ عَنْكُمْ
سَيِّئَاتِكُمْ وَنُدْخِلْكُمْ مُدْخَلًا كَرِيمًا) النساء: ٣١

Мәгънәсе: **«Әгәр Аллаһ тыйган гөнаһлы эшләрнең зурларыннан саклансагыз, ягъни фарыз кылынган гамәлләрне үтәп, фәхеш, хәрам һәм бидгать гамәлләрдән ерак булсагыз, кечкенә гөнаһларыгызны җуярбыз һәм сезне хөрмәтләп Җәннәтләргә кертербез».**

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Аллаһ тәгаләнең кешегә биргән иң зур нигъмәте нәрсә?

2) Иманның иң югары тармагы нәрсә?

3) Иманның иң түбән тармагы нәрсә?

4) Нәрсә ул иман?

5) Нәрсә ул гөнаһ?

6) Кәфер белән мәгъсыять кылучы арасында нинди аерма?

7) Зур гөнаһлар белән кечкенә гөнаһлар арасында нинди аерма?

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) ____________ кешегә бирелгән иң зур ____________.

2) Иманның ______________ яки ________________ артык тармагы бар, иң яхшысы вә иң югарысы ______________________________ дип әйтү, ә иң түбәне ______________________________.

3) _________________ иманның бер тармагы.

4) Иман — ул ______________________, йөрәк белән раслау, ныгыту вә ______________________.

5) Гөнаһ кылу _______________ тискәре ___________ итә.

6) Ширек _______________ юкка чыгара.

7) Зур гөнаһларга __________, ___________, ___________, ___________, һәм башкалар керә.

# Җиденче дәрес

## Фәрештәләргә иман

### Фәрештәләргә иманның мәгънәсе:

Фәрештәләр алар нурдан яратылган Аллаһ тәгаләнең мәхлуклары дип инану, ныклы ышану тиешле. Ашамыйлар, эчмиләр һәм Аллаһка буйсынып, Аның кушканнарын гына үтиләр.

(لَا يَعْصُونَ اللَّهَ مَا أَمَرَهُمْ وَيَفْعَلُونَ مَا يُؤْمَرُونَ) التحريم: ٦

Мәгънәсе: **«Алар (фәрештәләр) үзләренә булган боерыкларда, Аллаһка һич хыйлафлык кылмаслар, Аннан нинди боерык булса — шуны эшләрләр».**

(يُسَبِّحُونَ اللَّيْلَ وَالنَّهَارَ لَا يَفْتُرُونَ) الأنبياء: ٢٠

Мәгънәсе: **«Кич вә көндез Аллаһны мактап тәсбих әйтерләр һәм алар тәсбихтән һич тә арымаслар вә туктамаслар».**

### Фәрештәләрнең зур дәрәҗәле булулары:

Фәрештәләрнең зур дәрәҗәле икәнлекләрен билгеләп, пәйгамбәребезгә салават кылганда Аллаһ тәгалә аларны Үзе белән бергә янәшә әйтеп узды:

(إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ) الأحزاب: ٥٦

Мәгънәсе: **«Аллаһ Үзе вә фәрештәләре пәйгамбәргә салават әйтәләр».**

Аллаһ Сөбханәһү вә тәгалә Коръәннең бик күп сүрәләрендә фәрештәләрне хөрмәт итеп, алар белән ант итте. Мәсәлән: «Саффат», «Мүрсәләт», «Нәзигать». Чөнки алар Аллаһка бөек гыйбадәт кылалар һәм бик каты курку илә куркалар.

(وَهُمْ مِنْ خَشْيَتِهِ مُشْفِقُونَ) الأنبياء: ٢٨

Мәгънәсе: **«Һәм алар Аллаһтан куркып түбәнчелек кылучылар».**

**Фәрештәләрнең мәртәбәләре:**

Коръән Кәрим фәрештәләрне бик күп урыннарда искә алды. Мәсәлән: Җибрил, Микәиил, Исрафил — алар барысы да тереклек белән йөкләнгән фәрештәләр. Җибрил — ул, йөрәкләрнең вә җаннарның тереклеге булган вәхи белән йөкләнгән. Микәиил — ул, җирнең, үләннәрнең вә хайваннарның тереклеге булган яңгыр белән йөкләнгән, ә Исрафил — ул, мәхлуклар үлгәннән соң Кыяммәттә кире терелүгә сәбәп булган Сурга өрү белән йөкләнгән. Шулай ук фәрештәләр арасыннан Гарешне күтәрү белән, барча гамәлләрне язып тору белән, саклау белән, Җәһәннәм уты һәм Җәннәт сакчылары, җаннарны алу вә кабердә

кешенең дине, Раббысы вә пәйгамбәре хакында сорау алу белән йөкләнгәннәре бар.

**Фәрештәләргә иман китерүнең фарызлыгы:**

Фәрештәләргә иман китерү гомуми дә[5], һәм тәфсыйлләп тә[6] фарыз. Нинди фәрештәләрнең исемнәре яки гамәлләре тәгаенләп искә алынмаган икән, без аларга гомуми ышанырга тиеш, ә кайсыларыныкы аерым тәгаенләп искә алынган булса, без аларга тәфсыйлләп, яки ничек искә алынган икән, шулай ышанырга тиеш. Фәрештәләрнең саннарына килгәндә, аны Аллаһ тәгаләдән башка һичкем белми:

(وَمَا يَعْلَمُ جُنُودَ رَبِّكَ إِلَّا هُوَ) المدثر: ٣١

Мәгънәсе: **«Раббыңның гаскәрләрен Аллаһтан башка һичкем белми».**

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Фәрештәләргә иманның мәгънәсен аңлат.

2) Аллаһ тәгалә фәрештәләрне Коръәндә ничек сыйфатлады?

3) Ни өчен Аллаһ тәгалә Коръәндә фәрештәләрне Үзе белән янәшә искә алды?

---

5 Барча фәрештәләргә бергә

6 Җентекләп, аерым-аерым билгеләп

4) Нинди фәрештәләрне Аллаһ тереклек белән йөкләде?

5) Ошбу аятьне аңлат:

(وَمَا يَعْلَمُ جُنُودَ رَبِّكَ إِلَّا هُوَ) المدثر: ٣١

Мәгънәсе: **«Раббыңның гаскәрләрен Аллаһтан башка һичкем белми».**

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Фәрештәләр Аллаһ тәгаләгә __________ тәсбих кылалар һәм Аның кушканнарын ________________.

2) Фәрештәләрнең зур _____________ икәнлекләрен билгеләп, пәйгамбәребезгә _____________ кылганда Аллаһ тәгалә аларны Үзе белән _____________ әйтеп узды.

3) Җибрил — ул, йөрәкләрнең вә _____________ тереклеге булган _____________ белән йөкләнгән.

4) Микәиил — ул, җирнең, _____________ вә хайваннарның тереклеге булган ___________________ белән йөкләнгән.

5) Исрафи — ул __________________ үлгәннән соң Кыямәт көнендә ___________________ сәбәп булган _____________ өрү белән йөкләнгән.

6) _____________ саннарына килгәндә, аны __________ башка һичкем белми.

## Сигезенче дәрес

### Китапларга иман

**Китапларга иманның мәгънәсе:**

Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгаләнең сүзе булган, пәйгамбәрләргә вә расүлләргә иңдергән китаплары бар, дип инану, ныклы ышану тиешле. Ул китап — хак, кешеләргә туры юлны күрсәтүче нур. Без барча иңдерелгән китапларга да иман китерергә тиешбез. Алар күп булуга карамастан безгә билгеле булганнары: Ибраһимгә ﵇ сахифәләр, Мусага ﵇ Тәүрат, Гыйсәгә ﵇ Инҗил, Давыдка ﵇ Зәбүр һәм Мөхәммәдкә ﷺ Коръән иңдерелде.

Коръәннән башка барча китаплар да кешеләр тарафыннан үзгәртелеп вә бозылып беттеләр. Коръәнне үзгәрешләрдән Аллаһ тәгалә Үзе саклавы хакында вәгъдә итте:

(إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ) الحجر: ٩

Мәгънәсе: **«Дөреслектә, Без Коръәнне Үзебез иңдердек һәм үзгәрүдән аны Үзебез сакларбыз».**

(لَا يَأْتِيهِ الْبَاطِلُ مِنْ بَيْنِ يَدَيْهِ وَلَا مِنْ خَلْفِهِ
تَنْزِيلٌ مِنْ حَكِيمٍ حَمِيدٍ) فصلت:٤٢

Мәгънәсе: **«Ул Коръәннең алдыннан да вә артыннан да батыл[7] килмәс, ягъни Коръән иңгән елларда да, хәзерге көндә дә Коръән Кәримне вә аның хөкемнәрен, вәгазьләрен юкка чыгара торган көч вә куәт дөньяда табылмады һәм табылмас. Ул Коръән, эшендә вә мәхлукатларында гадел һәм хәким, камил сыйфатларында мактаулы булган — Аллаһтан иңдерелмеш».**

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Китапларга иманның мәгънәсен аңлат.

2) Аллаһ тәгалә нинди китаплар иңдерде?

3) Кайсы пәйгамбәрләргә китаплар иңдерелде?

4) Аллаһ тәгалә Коръәнне үзгәрешләрдән саклавы хакында дәлил китер.

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Коръәннән башка барча ______________ да кешеләр тарафыннан ______________ вә ______________ беттеләр.

2) Аллаһ тәгалә ______________ Гыйсәгә عليه السلام иңдерде.

7 Бишенче биттә

3) Аллаһ тәгалә ______________ Давыдка عليه السلام индерде.

4) Аллаһ тәгалә _____________ үзгәрешләрдән саклавы хакында _________________ итте.

# Тугызынчы дәрес

## Пәйгамбәрләргә иман

### Пәйгамбәрләргә иманның мәгънәсе:

Аллаһ тәгалә бәндәләргә бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешү өчен туры юлны күрсәтүче пәйгамбәрләр җибәрде, дип инану, ныклы ышану тиешле. Алар үзләренә йөкләнгән пәйгамбәрлекне тиешенчә үтәп, җиткергән хәбәрләрендә тугры булдылар. Һәм өммәтләрне нәсыйхәт кылып, нинди хәерле гамәл булса — шуңа өндәделәр вә нинди бозыклык булса — шуннан тыйдылар һәм кисәттеләр. Аларга кем итагать кылса — шуларны Җәннәт белән шатландырдылар, ә кемнәр аларга каршылык күрсәтеп, буйсынмый торган булсалар — шуларны Җәһәннәм уты көткәнлеге белән кисәттеләр.

(رُسُلًا مُبَشِّرِينَ وَمُنْذِرِينَ لِئَلَّا يَكُونَ لِلنَّاسِ عَلَى
اللَّهِ حُجَّةٌ بَعْدَ الرُّسُلِ) النساء: ١٦٥

Мәгънәсе: **«Расүлләр үзләренең бурычларын үтәгәннән соң, ахирәттә динсезләр: «Әй Аллаһ, безгә китап иңдермәдең, расүлләр күндермәдең», — дип аклану булмасын өчен, Аллаһ тәгалә Аңа итагать итүче хак мөэминнәрне Җәннәт белән шатландыручы һәм Аллаһка**

**итагать итмәүчеләргә Җәһәннәм газабы булачагы белән хәбәр бирүче пәйгамбәрләрне җибәрде».**

**Пәйгамбәрләрнең саны һәм кайсыларына карата тәфсыйлләп[8] иман китерү тешле:**

Пәйгамбәрләр күп һәм аларның санын Аллаһ тәгаләдән башка һичкем белми:

(وَرُسُلًا قَدْ قَصَصْنَاهُمْ عَلَيْكَ مِنْ قَبْلُ وَرُسُلًا
لَمْ نَقْصُصْهُمْ عَلَيْكَ) النساء: ١٦٤

Мәгънәсе: **«Янә, элек сиңа кайбер пәйгамбәрләрне бәян иттек һәм кайбер пәйгамбәрләрне сиңа бәян итмәдек».**

Коръәндә искә алынган пәйгамбәрләр егерме биш: Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Ибраһим, Лут, Йунус, Исмәгыйль, Исхакъ, Ягъкуб, Йусуф, Әйүб, Шүгайб, Муса, Һарун, Әлясәгъ, Зүл-Кифел, Давыд, Зәкәрия, Сөләймән, Ильяс, Яхъя, Гыйсә һәм Мөхәммәд ﷺ.

**Расүлләрдән булган «Үлү әл-Газм»** (базымлы, сабырлык, кыюлык хуҗалары): Нух, Ибраһим, Муса, Гыйсә һәм Мөхәммәд ﷺ. Аларны Аллаһ тәгалә Коръән Кәримнең «әш-Шүра» сүрәсендә искә алып болай диде:

(شَرَعَ لَكُمْ مِنَ الدِّينِ مَا وَصَّى بِهِ نُوحًا وَالَّذِي أَوْحَيْنَا
إِلَيْكَ وَمَا وَصَّيْنَا بِهِ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَى وَعِيسَى أَنْ

8 Җентекләп, аерым-аерым билгеләп

أَقِيمُوا الدِّينَ وَلَا تَتَفَرَّقُوا فِيهِ﴾ الشورى: ١٣

Мәгънәсе: **«Без сезгә диндә шәригать төзеп бирдек, ул шәригатьне Нухка вә сиңа, әй Мөхәммәд, вә Ибраһимгә вә Мусага вә Гыйсәгә васыять иттек, ягъни: «Без төзегән шул хак дин шәригатен тотыгыз, хөкемнәрен бозмагыз, шәригатьне үзгәртмәгез һәм төрле фиркаларга, төрле мәзхәбләргә бүленмәгез», — дип йөкләдек, һәр пәйгамбәргә вә мөселманга әмер иттек».**

**Пәйгамбәрләр — алар кешеләр затыннан:**

Кешеләрдә булган табигый сыйфатларның барчасы да пәйгамбәрләрдә дә бар. Мәсәлән: Йоклау, ашау, эчү, утыру, йөрү, көлү, авыру, өйләнү, шулай ук аларга залимнар кулы сузыла, һәм алар җәберләү вә авырту сизәләр. Аларның кайберләре золымлык белән хаксыз үтерелделәр:

﴿وَيَقْتُلُونَ الْأَنْبِيَاءَ بِغَيْرِ حَقٍّ﴾ آل عمران: ١١٢

Мәгънәсе: **«Вә пәйгамбәрләрне хаксыз үтерәләр».**

Сөекле пәйгамбәребез дә ﷺ авырый торган иде, эссене вә суыкны, ачлыкны вә сусауны, һәм шулай ук башка кешеләр кебек үк авырлыкларны сизә иде. Пәйгамбәрләр башка кешеләр кыла торган гөнаһлы эшләрдән вә начар сыйфатлардан имин һәм ерак булдылар.

**Аллаһ тәгалә пәйгамбәрләрне могҗизалар белән ныгытты:**

Пәйгамбәрләр искиткеч күркәм әхлак, сабырлык, гаделлек, кыюлык һәм башка, аларның пәйгамбәр икәнлекләрен күрсәтә торган гүзәл сыйфатлар белән сыйфатлануларына карамастан, Аллаһ тәгалә аларның дөреслеген вә хаклыгын исбатлап могҗизалар белән ныгытты. Мәсәлән: Мусаның таягы, Салихның дөясе, шулай ук Гыйсәгә бирелгән могҗизалар һәм башкалар.

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Кемнәр алар «Үлү әл-Газм»?

2) Аларның исемнәре искә алынган аятьне әйт.

3) Пәйгамбәрләргә иманның мәгънәсен әйт.

4) Ни өчен Аллаһ пәйгамбәрләр җибәрде?

5) Пәйгамбәрләр үзләренә итагать иткәннәрне нәрсә белән шатландырдылар?

6) Пәйгамбәрләр үзләренә итагать итмәгәннәрне нәрсә белән куркыттылар?

7) Пәйгамбәрләр гади кешеләрдән нәрсә белән аерылалар?

8) Аллаһ пәйгамбәрләрне нәрсә белән ныгытты?

# Унынчы дәрес

## Ахирәт көненә иман

### Ахирәт көненә иманның мәгънәсе:

Коръәндә һәм пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтендә килгән үлемнән соң була торган кабер фетнәсе, газабы вә нигъмәте, Зур Кыямәттә була торган кубарылу, хисаб, мизан, Җәннәт вә Җәһәннәм хак, дип инану (ныклы ышану) тиешле.

### Кабер фетнәсе:

Фетнә дигән сүз монда, «имтихан» мәгънәсендә килә. Чөнки кеше кабердә: «Раббың кем? Динең нинди? Пәйгамбәрең кем?», — дип соралачак. Аллаһ тәгалә, иман китергән кешеләрне бу дөньяда да, ахирәттә дә хак, тугры сүз белән ныгыта, һәм мөэмин: «Раббым — Аллаһ, динем — Ислам, пәйгамбәрем — Мөхәммәд», — дип җавап бирәчәк. Әмма кәфер: «Ах-ах, белмим, кешеләрдән нәрсәдер ишеткән идем, шуны әйттем», — дип хәсрәткә батачак.

### Кабер газабы һәм нигъмәте:

Кабер фетнәсеннән соң, кешене Зур Кыямәткә кадәр газап яки нигъмәт көтә.

Аның кабере Җәннәтнең бер бакчасына яки Җәһәннәм утының бер чокырына әйләнә. Кабер газабының хаклыгы турында, Аллаһ тәгалә Коръәндә Фиргавен кавеме хакында әйткән ошбу аятьләрне китерергә була:

(النَّارُ يُعْرَضُونَ عَلَيْهَا غُدُوًّا وَعَشِيًّا وَيَوْمَ تَقُومُ السَّاعَةُ
أَدْخِلُوا آلَ فِرْعَوْنَ أَشَدَّ الْعَذَابِ) غافر: ٤٦

Мәгънәсе: **«Алар иртә дә, кич тә ут газабына дучар ителер, әмма Кыямәт көне булгач: «Фиргавен кавемен газабның катысына кертегез», — диелер».**

**Зур Кыямәт:**

Әл-Бәрзәх[9] вакыты беткәннән соң, Зур Кыямәт башлана. Җаннар дөньяда булган үз тәннәренә кайтып, кешеләр каберләреннән кубарылып, Раббылары каршына басарлар.

(أَلَا يَظُنُّ أُولَئِكَ أَنَّهُمْ مَبْعُوثُونَ لِيَوْمٍ عَظِيمٍ يَوْمَ
يَقُومُ النَّاسُ لِرَبِّ الْعَالَمِينَ) المطففين: ٤-٦

Мәгънәсе: **«Әллә алар Олуг Кыямәт көнендә терелеп кубарылачакларын уйламыйлармы? Ул көндә кешеләр, барча галәмне тәрбия итүче Аллаһ хозурында хисаб өчен басып торырлар».**

Бу Кыямәт хакында Аллаһ Коръәндә, һәм пәйгамбәребез ﷺ хәдисләрендә хәбәр итте.

9 Дөнья белән ахирәт арасындагы, тәннәр кабердән кубарылганчыга кадәр булган үлем вакыты

**Мизан:**[10]

Ул — Кыямәт көнендә бәндәләрнең гамәлләрен үлчи торган хакыйкый үлчәү.

(وَالْوَزْنُ يَوْمَئِذٍ الْحَقُّ فَمَنْ ثَقُلَتْ مَوَازِينُهُ فَأُولَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ۞ وَمَنْ خَفَّتْ مَوَازِينُهُ فَأُولَئِكَ الَّذِينَ خَسِرُوا أَنْفُسَهُمْ بِمَا كَانُوا بِآيَاتِنَا يَظْلِمُونَ) الأعراف: ٨ - ٩

Мәгънәсе: **«Кыямәт көнендә булачак савап илә гөнаһны үлчәү мизаны хак, берәүнең үлчәүдә изгелеге авыр булып начар гамәлләре җиңел килсә, алар газаптан котылып өстенлек табучылар. Вә берәүнең үлчәүдә изге гамәлләре җиңел булып начар гамәлләре авыр килсә, андый кешеләр гамәл кылмыйча аятьләребезгә золым иткәннәре өчен һәлак булучылар».**

**Гамәл дәфтәре:**

Ул — бәндәләрнең бу дөньяда кылган барча гамәлләрен язып баручы фәрештәләрнең дәфтәре. Кыямәт көнендә ул язмалар хуҗаларына таратылыр. Мөэмин кеше үзенең гамәлләре язылган сахифәне уң кулы белән алыр, ә кем Аллаһка итагать кылмаган булса, ул сахифәсен сул кулы белән яки арттан сул кулына алыр.

(وَإِنَّ عَلَيْكُمْ لَحَافِظِينَ ۞ كِرَامًا كَاتِبِينَ ۞ يَعْلَمُونَ مَا تَفْعَلُونَ) الانفطار: ١٠-١٢

10 Үлчәү

Мәгънәсе: **«Әлбәттә, шиксез, сезнең өстегездә сакчы фәрештәләр бар. Ул фәрештәләр Аллаһ хозурында хөрмәтлеләр, алар сезнең барча гамәлләрегезне язучылар. Сезнең кылган эшләрегезне бик яхшы белүчеләр».**

(فَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ بِيَمِينِهِ ۞ فَسَوْفَ يُحَاسَبُ حِسَابًا يَسِيرًا ۞ وَيَنْقَلِبُ إِلَى أَهْلِهِ مَسْرُورًا ۞ وَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ وَرَاءَ ظَهْرِهِ ۞ فَسَوْفَ يَدْعُو ثُبُورًا) الانشقاق: ٧ - ١١

Мәгънәсе: **«Әмма гамәл дәфтәре уң тарафтан бирелгән кеше, җиңел хисаб ителер. Ул Җәннәттәге әһеленә шатланып барыр. Вә әмма гамәл дәфтәре арттан сул тарафыннан бирелгән кеше, тиздән үзенә һәлакәтлекне чакырыр».**

**Хисаб:**

Аллаһ тәгалә мәхлукларның гамәлләрен яхшы булса да, начар булса да хисаб кыла. Мөэмин кеше җиңел хисаб ителер, аңа гөнаһлары күрсәтелер һәм ул аларны таныр.

(فَأَمَّا مَنْ أُوتِيَ كِتَابَهُ بِيَمِينِهِ ۞ فَسَوْفَ يُحَاسَبُ حِسَابًا يَسِيرًا)

Мәгънәсе: **«Әмма гамәл дәфтәре уң тарафтан бирелгән кеше, җиңел хисаб ителер».**

Әмма кәфер каты вә авыр хисаб кылыныр, хәтта ул хисабның катылыгыннан куркып, үзенең туфрак булуын теләр:

(يَوْمَ يَنْظُرُ الْمَرْءُ مَا قَدَّمَتْ يَدَاهُ وَيَقُولُ الْكَافِرُ
يَا لَيْتَنِي كُنْتُ تُرَابًا) النبأ: ٤٠

Мәгънәсе: **«Ул көндә һәркем үзенең гамәл дәфтәренә карар, Коръәнне инкяр итүче яки аның белән гамәл кылмаучы кәфер әйтер: «Әгәр мин туфрак булсамчы».** (Хисаб, хөкем соңында Аллаһ хайваннарны туфрак итәр. Кәферләр дә үзләренең туфрак булуларын теләрләр, ләкин туфрак була алмаслар).

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Нәрсә ул ахирәт көненә иман?

2) Нәрсә ул кабер фетнәсе?

3) Кабердә мәеттән нәрсә сорала?

4) Кабер газабын исбатлаган аятьне әйтеп уз.

5) Халыклар үзләренең гамәлләре өчен кайчан хисабланалар?

6) Ни өчен кәфер туфрак булуын теләр?

# Унберенче дәрес

## Хәуд (Сулык) һәм Сыйрат (күпер)

### Хәуд:

Ул — пәйгамбәребезнең ﷺ Сулыгы. Ислам өммәте Кыямәт көнендә шул сулыкка килеп, үзләренең сусаганнарын басарлар. Анының суы сөттән ак, балдан ләззәтлерәк, һәм анының янында булган, су эчә торган савытлар, күктәге йолдызлар кебек күп. Ул Сулыкның буе бер айлык юл булса, киңлеге дә шулай ук бер айлык юл. Кем дә кем аннан бер йотым эчсә, беркайчан да сусамас.

### Сыйрат:

Ул — Җәннәткә чыга торган, Җәһәннәм өстендәге күпер. Кешеләр ул күперне үзләренең гамәлләренә карата үтәрләр. Кемдер аны күз ачып йомганчы үтәр, кемдер яшен тизлегендә, кемдер җил тизлегендә, кемнәрдер чабыш аты тизлегендә, икенчеләре дөя тизлегендә, кайсылары йөгереп үтәр, кемдер җәяүләп-атлап узар, ә кемдер ул күперне шуышып үтәр, ә кемнәрдер Җәһәннәмгә ыргытылыр. Ул күпердә ыргаклар бар, һәм кешеләрне гамәлләренә карата шул ыргаклар эләктереп алыр вә Җәһәннәмгә ташлар. Кем шул күперне узган булса, Җәннәт

белән Җәһәннәм арасындагы урында җыелыр вә Аллаһ тәгалә аларның үз араларында бер-берсенә карата булган хаталарын хөкем итәр. Һәрберсе үзенә тиешлесен алып, бер-берсе арасында булган хаталардан тазарынгач вә пакьләнгәч, аларга Җәннәткә керергә рөхсәт бирелер. Иң беренче булып Җәннәт ишеген пәйгамбәребез ﷺ ачар.

Без белергә тиеш: Кем дә кем ошбу дөньяда Аллаһ тәгаләнең динендә, туры юлында ныклы тора икән, ул Кыямәт көнендә Сыйрат күперендә дә ныклы торачак. Ә кем бу дөньяда туры юлдан тайпылган булса, ул Кыямәт көнендә Сыйрат күпереннән дә тайпылып Җәһәннәмгә ыргытылыр. Ошбу Сыйратта монафиклар белән мөэминнәр аерылыр. Ни куркыныч ул монафикларның вә кәферләрнең барачак урыны. Аллаһ сакласын! Раббыбыз аякларыбызны дин Исламыбызда ныклы кылсын һәм Фирдәвес Җәннәтләренә ирештерсен! Әмин!!!

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Җәннәт ишекләре иң беренче кемгә ачыла?

2) Нәрсә ул Хәуд?

3) Хәудның суын сыйфатла.

4) Нәрсә ул Сыйрат?

5) Кешеләр Сыйратны ничек үтәрләр?

6) Сыйратны узгач кешеләр кайда җыелырлар, һәм ни өчен?

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Хәуд ________________ Сулыгы.

2) Ул Сулыкның буе ______________ һәм киңлеге дә ______________ .

3) ______________ чыга торган ______________ өстендәге ______________ ______________ дип атала.

4) Иң беренче булып ______________ ишеген ________________ ача.

# Уникенче дәрес

## Кадар (тәкъдир)

**Тәкъдирнең мәгънәсе:**

Кадар — ул, барча мәхлукларны да бар кылганчы белгән, Аллаһ тәгаләнең гыйлеме, һәм Үзенең гыйлеменә карата теләге вә кодрәте белән, ул мәхлукларны халикъ кылуы.

Тәкъдиргә иман китерүнең ике шарты бар:

**Беренче:** Бәндәләрне халикъ кылганчы Аллаһ тәгалә аларның яхшы яки начар гамәл кыласыларын белә иде, һәм алар, Аңарда Ләүхул-Мәхфузда язылган, дип иман китерү.

**Икенче:** Аллаһ тәгалә бәндәләрнең барча гамәлләрен халикъ кылды, һәм алардан шуны теләде, дип иман китерү.

Яки моны икенче төрле әйткәндә, тәкъдирнең мәртәбәләре, дип дүрткә бүлергә була:

**1. Гыйлем.** Аллаһ тәгалә күкләрдә һәм җирдә, Үзенә хас булган һәм мәхлукларның фигыльләреннән булган, барча нәрсәне дә белә, Аннан һичнәрсә дә яшеренеп кала алмый, дип инану (ныклы ышану) тиешле.

**2. Китәбә,** яки барча нәрсәнең дә Аллаһ тәгаләдә Ләүхул-Мәхфузда язылуы. Аллаһ тәгалә барча мәхлукларның да язмышын

Үзендә Ләүхул-Мәхфузда язды, дип инану. Татарларда бу язылган тәкъдир «Язмыш», — дип тә атала. Бу ике мәртәбә турында түбәндәге аятьне китерергә мөмкин:

(أَلَمْ تَعْلَمْ أَنَّ اللهَ يَعْلَمُ مَا فِي السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ إِنَّ ذَلِكَ
فِي كِتَابٍ إِنَّ ذَلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرٌ) الحج: ٧٠

Мәгънәсе: **«Әллә белмәдеңме Аллаһның җирдәге вә күкләрдәге нәрсәләрне белгәнлеген? Алар барчасы да Ләүхүл-Мәхфуздагы китапта язылган, сезне хөкем итү вә һәрнәрсәне белү, Аллаһка җиңел».**

Аллаһ тәгалә беренче һәрнәрсәне белгәнлеген хәбәр итте, аннары ул нәрсәләрнең барысы да Ләүхүл-Мәхфузда язылган дип бәян кылды.

**3. Ирадә,** яки теләк. Барча нәрсә Аллаһның теләге буенча. Ул нәрсәнең булуын теләсә — шул була, ә нәрсәнең булуын теләмәсә — ул булмый. Моңа түбәндәге аятьләрне китерергә мөмкин:

(لِمَنْ شَاءَ مِنْكُمْ أَنْ يَسْتَقِيمَ ۞ وَمَا تَشَاءُونَ إِلَّا أَنْ
يَشَاءَ اللهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ) التكوير: ٢٨ - ٢٩

Мәгънәсе: **«Сезләрдән туры юлга күнелергә теләге булган кешеләр. Юк туры юлга күнелүне тели алмассыз, иллә-мәгәр барча галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһ тәгалә теләсә генә».**

(وَلَوْ شِئْنَا لَآتَيْنَا كُلَّ نَفْسٍ هُدَاهَا) السجدة: ١٣

Мәгънәсе: **«Әгәр Без теләсәк, һәр кешегә иманны вә һидәятне бирер идек».**

(وَلَوْ شَاءَ رَبُّكَ لَجَعَلَ النَّاسَ أُمَّةً وَاحِدَةً) هود: ١١٨

Мәгънәсе: **«Әгәр Раббың теләсә иде, бөтен кешеләрне дә бер диндә кылыр иде».**

**4. Халикъ кылу.** Барча нәрсәне дә Аллаһ тәгалә халикъ кылды (булдырды) дип инану. Булсын ул җирдә яки күкләрдә, хәтта кешенең үзе артыннан тормышның юклыгын алып килә торган үлемне дә, Аллаһ халикъ кылды.

(الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا) الملك: ٢

Мәгънәсе: **«Ул үлемне һәм тереклекне халикъ кылды, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген йөкләмәләр йөкләп, сезне сынамак өчен».**

Тәкъдиргә ышану — Коръән вә Сөннәттә килүенчә, Иманның бер рөкене (нигезе) булып тора. Аллаһ тәгалә нәрсә теләсә — шул була, ә нәрсәне теләмәсә — ул булмый. Шуның өчен дә, безгә тәкъдирнең хәерлесенә дә, начарына да иман китерү — фарыз. Аллаһ безгә мөмкинчелек вә теләк бирде, шуңа да безнең гамәлләребез — ошбу ике әйбернең нәтиҗәсе, һәм шуның өчен дә соралачакбыз.

**Тәкъдиргә иманның ничеклеге:**

Пәйгамбәребез ﷺ тәкъдиргә иманның ничек булганлыгын үзенең хәдис шәрифендә болай дип бәян итте:

«لا يُؤمِنُ عَبْدٌ حَتَّى يُؤمِنَ بِالْقَدَرِ خَيْرِهِ وَ شَرِّهِ حَتَّى يَعْلَمَ أنّ ما أصابَهُ لَمْ يَكُنْ لِيُخْطِئَهُ، وَ ما أَخْطَأَهُ لَمْ يَكُنْ لِيُصِيبَهُ» (رواه الترمذي)

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кеше тәкъдирнең яхшысына да, начарына да ышанмыйча, һәм аны (нигъмәттән яки бәладән, итагатьтән яки мәгъсыятьтән) читтән әйләнеп узган әйбер аңа ирешә алмый, ә аңа ирешкәне (яхшысы яки начары) ул кешене читләтеп үтә алмый икәнлеген белмичә торып, иманлы булмас».***

**Тәкъдирләрнең язылуы:**

Аллаһ тәгалә барча нәрсәнең тәкъдирен, мәхлукларны халикъ кылганчы Ләүхул-Мәхфузда язды:

(مَا أَصَابَ مِنْ مُصِيبَةٍ فِي الْأَرْضِ وَلَا فِي أَنْفُسِكُمْ إِلَّا فِي كِتَابٍ مِنْ قَبْلِ أَنْ نَبْرَأَهَا إِنَّ ذَلِكَ عَلَى اللهِ يَسِيرٌ) الحديد: ٢٢

Мәгънәсе: **«Җирдә вә үзегезгә бәла-каза ирешмәде, иллә-мәгәр ирешә икән — ул бәла-каза халикъ кылынганчы ук Ләүхул-Мәхфузда язылган, тәхкыйк, бу эш Аллаһка бик җиңел».**

عن عبادة بن الصامت رضي الله عنه قال: سمعت رسول الله صلى الله عليه و سلم يقول: «إنّ أوّلَ ما خَلَقَ الله الْقَلَمَ، فَقَالَ لَهُ: اُكْتُبْ!

قَالَ: وَ ما أَكْتُب؟ قَال: اُكْتُب مَقَادِيرَ كُلّ شَيء إِلى أَنْ تَقُومَ السّاعَة» (سنن أبي داوود)

Гүбәдә бин әс-Самиттән ﵁: Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Иң беренче Аллаһ тәгалә каләмне халикъ кылды, һәм әйтте аңа: «Яз!». Каләм әйтте: «Нәрсә языйм?». Аллаһ әйтте: «Барча әйберләрнең Кыя-мәт сәгате җиткәнчегә кадәр булган тәкъдирен яз!».***

عن عبد الله بن عمروبن العاص رضي الله عنه قال: سَمِعْتُ رَسُولَ اللهِ صَلّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ يَقُولُ: «كَتَبَ اللهُ مَقَادِيرَ الْخَلْق قَبْلَ أَنْ يَخْلُقَ السَّماواتِ وَ الأَرْضَ بِخَمْسِينَ أَلْفَ سَنَةٍ قَالَ وَ عَرْشُهُ عَلَى الْمَاء» (مسلم )

Шулай ук, Габдуллаһ бин Гамрдән ﵁ килгән хәдистә пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә күкләр белән җирне халикъ кылганчы илле мең ел алдан элек барча мәхлукларның тәкъдирләрен язды»,*** әйтте: ***«һәм Аның Гареше су өстендә иде».***

Сахәбәләрдән, тәбигыйннардан вә изге сәләфләрдән булган сөннәт әһелләре игътикады буенча: Аллаһ тәгалә һәрнәрсәне белә, һәм Кыямәт сәгатенә кадәр булачак вә булган барча әйберләрне язды. Ул — барча әйберләрнең Раббысы вә Халикъ кылучысы. Хакыйкатьтә, бәндәләрнең фигыльләре Аллаһ тәгалә тарафыннан бар ителде һәм Аның теләгеннән. Ул фигыльләр бәндәләрнеке вә аларның үзләренең

ихтияры белән кәсеб ителгән фигыльләр, шуның өчен дә эшләгән гамәлләренә әҗер-савап яки гыйкаб (җәза) алалар. Шулай ук, сөннәт әһелләреннән булганнар, тәкъдир мәсъәләләренә тиешлесеннән артыгына кереп төпченмиләр вә бәхәсләшмиләр, чөнки ул Аллаһ тәгаләнең мәхлукларында булган серләреннән, һәм Аннан башка ул серләрне, хәтта пәйгамбәрләр дә вә фәрештәләр дә белми.

Бервакыт, Мәккә курайшларыннан булган кәферләр пәйгамбәребез ﷺ янына килеп, тәкъдир мәсъәләсендә бәхәсләшә башлагач, Аллаһ тәгалә ошбу аятьләрне иңдерде:

(يَوْمَ يُسْحَبُونَ فِي النَّارِ عَلَى وُجُوهِهِمْ ذُوقُوا مَسَّ سَقَرَ ۞ إِنَّا كُلَّ شَيْءٍ خَلَقْنَاهُ بِقَدَرٍ) القمر: ٤٨ - ٤٩

Мәгънәсе: **«Алар Кыямәт көнендә йөзтүбән утта өстерәлерләр, һәм аларга: «Сакар тамугының газабын татыгыз», — диелер. Тәхкыйк, Без һәрнәрсәне тәкъдир белән халикъ кылдык».**

Габдуллаһ бин Гомәр رضي الله عنه әйтте: «Аллаһ белән ант итәм, әгәр дә берәрсенең Үхүд тавы кадәр алтыны булып, хәтта шуны Аллаһ юлында садака итеп таратса да, тәкъдиргә иман китермичә торып Аллаһ аның садакасын кабул итмәс», — диде. Һәм шуннан соң, пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисен китерде: ***«Иман***

***— ул, Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Китапларына, Пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә, һәм тәкъдирнең яхшысына вә яманына ышану».***

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Нәрсә ул кадар (тәкъдир)?

2) Кадарга иманның ничеклеген аңлат.

3) Аллаһ тәгалә барча мәхлукларның тәкъдирен кайчан язды?

4) Ул тәкъдирләр кайда язылды?

5) Габдуллаһ бин Гомәр тәкъдирне инкяр иткән кеше турында нәрсә әйтте?

6) Сахәбәләрдән, тәбигыйннардан вә изге сәләфләрдән булган сөннәт әһелләренең тәкъдирдә булган игътикады ничек?

7) Ни өчен алар тәкъдирдә бәхәсләшүдән вә төпченүдән читләшүне уңай күрәләр?

8) Кадарга иман китерүнең ничә шарты бар? Яки кадарның мәртәбәләрен әйтеп уз.

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) _____________ — ул, барча _____________ да бар кылганчы белгән, Аллаһ тәгаләнең _____________, һәм Үзенең _____________ ка-

рата _____________ вә _____________ белән, ул мәхлукларны _____________ кылуы.

2) _____________ тәгалә барча нәрсәнең _________, мәхлукларны _____________ кылганчы _____________ язды.

3) Хакыйкатьтә, бәндәләрнең _____________ Аллаһ тәгалә тарафыннан _____________, һәм Анын _____________.

4) _____________ ышану — _____________ бер нигезе булып тора.

# Унөченче дәрес

## Сөннәт һәм бидгать

**Сөннәт** — юл дигәнне аңлата, ләкин аның **шәргый мәгънәсе:** Ул — пәйгамбәребезгә ﷺ тоташкан нәрсәләр. Булсын ул аның әйткән сүзләре, кылган фигыльләре яки нинди дә булса гамәлне күреп, аңа карата дәшмичә калганлыгы.

**Бидгать** — диндә яки тормышта кертелгән яңалык. Әмма **шәргый мәгънәсе:** Ул — Корънәндә, Сөннәттә, һәм шәригатебездә дә асылы булмаган, динебезгә кемнәрдер тарафыннан яңалык итеп кертелгән гыйбадәт.

Беләбез ки, пәйгамбәребез ﷺ өммәтенә Сөннәткә тотынырга вә бидгатьтән сакланырга, дип үзенең хәдисләрендә васыять әйтеп калдырды:

قَالَ عَلَيْهِ الصَّلاةُ وَ السَّلام: «عَلَيْكُمْ بِسُنَّتِى وَسُنَّةِ الْخُلَفَاءِ الرَّاشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ عَضُّوا عَلَيْهَا بِالنَّوَاجِذِ وَإِيَّاكُمْ وَالأُمُورَ الْمُحْدَثَاتِ فَإِنَّ كُلَّ بِدْعَةٍ ضَلاَلَةٌ» (رواه ابن ماجه و غيره، صحيح)

Мәгънәсе: ***«Сезгә минем сөннәтем, вә миннән соң килгән тугры хәлифләрнең сөннәте, нык-лап тотынығыз аңа һәм азау (урт) тешләрегез белән ябышыгыз, һәм бидгатьләрдән сакланыгыз, хакыйкатьтә, һәрбер бидгать — адашу».***

«مَنْ دَعَا إِلَى هُدًى كَانَ لَهُ مِنَ الأَجْرِ مِثْلُ أُجُورِ مَنْ تَبِعَهُ لاَ يَنْقُصُ

ذَلِكَ مِنْ أُجُورِهِمْ شَيْئًا وَمَنْ دَعَا إِلَى ضَلاَلَةٍ كَانَ عَلَيْهِ مِنَ الإِثْمِ مِثْلُ آثَامِ مَنْ تَبِعَهُ لاَ يَنْقُصُ ذَلِكَ مِنْ آثَامِهِمْ شَيْئًا» (رواه مسلم)

Мәгънәсе: ***«Кем дә кем һидәяткә[11] чакырды исә, аңа ияргән кешеләрнеке кебек әҗер-савап булыр, һәм аларның үзләренең әҗере һич кенә дә кимемәс. Ә кем дә кем адашуга чакырса, аңа ияргән кешеләрнеке кебек гөнаһ булыр, һәм аларның үзләренең гөнаһы һич кенә дә кимемәс».***

**Кемнәр алар сөннәт әһелләре (әһле-сүннә)?**

**Әһле-сүннә** — алар Сөннәт белән бәйле, һәм аңа бик каты итеп тотынучылар. Аларның асылы — Коръән вә Сөннәт. Сөннәтне өйрәнергә вә аңларга омтылалар, һәм башкаларны да шуңа чакыралар. Яхшылыкка, сабырлыкка, күркәм әхлакка, изге гамәлләргә, ата-анага карата яхшы мөгамәләдә булуга, туганлык җепләрен ныгытырга, күршеләр белән күркәм мөгамәлә итәргә, мескеннәргә вә ятимнәргә мәрхәмәтле булырга өндиләр һәм начарлыклардан тыялар.

Сөннәт әһелләренә дүрт мәзһәб имамнары да керә — имам Әбү Хәнифә, имам Мәлик, имам әш-Шәфигый һәм имам Әхмәд бин Хәнбәл.

---

11 Туры юл

## Күнегүләр

- Түбәндәге сорауларга җавап бир:

1) Нәрсә ул Сөннәт?

2) Нәрсә ул бидгать?

3) Пәйгамбәребез ﷺ өммәтенә нәрсә васыять итеп калдырды?

4) Пәйгамбәребез ﷺ өммәтен нәрсәдән кисәтте?

5) Кемнәр ул әһле-сүннә?

6) Алар нәрсәгә чакыра?

7) Әһле-сүннәнең асылы нәрсә?

- Җөмләләргә дөрес сүзләр куеп тулыландыр:

1) Мөселманнар кешеләрне ________________ өндиләр вә ______________________ тыялар.

2) Ислам шәригате ______________________ вә пәйгамбәребезнең ﷺ ___________________ нигезләнгән.

3) Әһле-сүннә алар ______________ белән бәйле һәм аңа __________________ итеп тотынучылар.

4) Әһле-сүннә ________________ читләшәләр.

5) Пәйгамбәребез ﷺ безгә____________________ һәм ______________________ тотынып яшәргә әмер итте.

- Түбәндәге сүзләр белән файдалы җөмләләр төзе: Тотынырга, туганлык җепләре,

юл, бидгать, Ислам, күркәм холык, сөннәт, ата-ана хакы, олыларга хөрмәт.

## Йомгаклау

*Әлхәмдулилләһ, Аллаһның теләге һәм ярдәме илә хәерле вә изге гамәлләр тәмамлана. Пәйгамбәребезгә ﷺ вә аның йорт әһелләренә, сахәбәләренә һәм Кыямәткә кадәр аңа ияргән барча кешеләргә салават вә сәламнәребез булсын!*

*Аллаһ Раббыбыз барча кимчелек вә хаталарыбызны ярлыкап, тәүбәләребезне кабул итсен! Һәммәбезне дә файдалы гыйлем, тәкъвалык, ихласлылык вә саф йөрәклелек илә зиннәтләсен!*

*Йә Раббым! Безне гамәлебездә дә, сүзебездә дә ихласлылык белән ризыкландыр, һәм дә изге сәләфләр кебек, пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтенә ияручеләрдән кыл, вә бидгатьләрдән читләштер! Аякларыбызны хаклыкта ныклы кыл, вә ике дөньяның да бәхетенә ирештер! Үзебезне, әни-әтиләребезне вә барча мөселманнарны ярлыка! Хакыйкатьтә, Син ишетүче, догаларны кабул итүче!*

# Эчтәлек

Кереш сүз........................................................3
**Беренче дәрес................................................6**
Нәрсә ул гакыйдә?..............................................6
Нәрсә ул Ислам гакыйдәсе?..............................7
Нәрсә ул тәүхид?................................................7
Тәүхиднең төрләре:...........................................7
Гакыйдә һәм гыйбадәт дөрес булуының шартлары.............................................................................8
Күнегүләр...........................................................9
**Икенче дәрес...............................................11**
Зур һәм кечкенә ширек....................................11
Ширек ничәгә бүленә?....................................12
Зур ширек белән кечкенә ширек арасындагы аермалар.......................................................................13
Күнегүләр.........................................................14
**Өченче дәрес...............................................16**
Ширекнең төрләре..........................................16
Күнегүләр.........................................................21
**Дүртенче дәрес.............................................23**
Мәетләр белән тәбәррүк кылу.........................23
Күнегүләр.........................................................25
**Бишенче дәрес..............................................26**
Аллаһның күркәм исемнәре һәм камил сыйфатлары..........................................................................26

Аллаһтәгаләнеңкүркәмисемнәренәвәсыйфатларына иман китерүнең мәгънәсе....................26
Күнегүләр..................................................29
**Алтынчы дәрес..........................................31**
Иманның тармаклары.......................................31
Иманның мәгънәсе.........................................31
Күнегүләр..................................................33
**Җиденче дәрес...........................................35**
Фәрештәләргә иман........................................35
Фәрештәләргә иманның мәгънәсе:.........................35
Фәрештәләрнең зур дәрәҗәле булулары......35
Фәрештәләрнең мәртәбәләре...............................36
Күнегүләр..................................................37
**Сигезенче дәрес..........................................39**
Китапларга иман...........................................39
Китапларга иманның мәгънәсе.............................39
Күнегүләр..................................................40
**Тугызынчы дәрес..........................................42**
Пәйгамбәрләргә иман......................................42
Пәйгамбәрләргә иманның мәгънәсе..............42
Күнегүләр..................................................45
**Унынчы дәрес..............................................46**
Ахирәт көненә иман.......................................46
Ахирәт көненә иманның мәгънәсе.................46
Кабер фетнәсе..............................................46
Кабер газабы һәм нигъмәте...............................46

Зур Кыямәт..........................................................47
Мизан.................................................................48
Гамәл дәфтәре....................................................48
Хисаб..................................................................49
Күнегүләр............................................................50
**Унберенче дәрес...............................................51**
Хәуд (Сулык) һәм Сыйрат (күпер)..................51
Хәуд....................................................................51
Сыйрат................................................................51
Күнегүләр............................................................52
**Уникенче дәрес.................................................54**
Кадар (тәкъдир)..................................................54
Тәкъдирнең мәгънәсе........................................54
Тәкъдиргә иман китерүнең шартлары............54
Тәкъдиргә иманның ничеклеге.........................57
Тәкъдирләрнең язылуы.....................................57
Күнегүләр............................................................60
**Унөченче дәрес.................................................62**
Сөннәт һәм бидгать...........................................62
Кемнәр алар сөннәт әһелләре (әһле-сүннә)?...................................................................63
Күнегүләр............................................................64
Йомгаклау...........................................................65